| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>НИЖНЕВЯЗОВСКОГО<br>ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>КАРАМАЛЫ ТАУ<br>ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ**
**12.11.2024**

пгт Н.Вязовые

**КАРАР**
**№ 219**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә җир эшләре башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча тапшыру турында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә Зеленодольск муниципаль районы Түбән Карамалы Тау шәһәр җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең җир эшләре башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшырырга.

2. Зеленодольск муниципаль районы Түбән Карамалы Тау шәһәр җирлеге башкарма комитетына әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты белән килешү төзергә.

3. Вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыруны тапшыру ел саен Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге бюджетыннан Зеленодольск муниципаль районы бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбеннән гамәлгә ашырыла.

4. «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең җир эшләрен гамәлгә ашыруга рөхсәт бирү буенча вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль

берәмлегенә тапшыру турында» 2024 елның 6 маендагы 193 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарны «Зеленодольская правда» газетасында урнаштырырга, әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында: Карамалы Тау ш.т.п., Беренче Май ур., 70 йорт, ҖҮИ административ бинасында мәгълүмат стенды, Беренче Май ур., 70 йорт (ҖҮИНЕҢ административ бинасы).

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Җирлек башлыгы,
Совет Рәисе

А.М. Гыйниятов